**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫНЫҢ**

Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**

Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
Советының

21 апрель 2021 ел № 8-59

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» гы Федераль закон, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы Кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга кушымта итеп бирелә торган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2008 ел, 29 апрель, 25-154 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек итү комиссиясе рәисенә йөкләнә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә
муниципаль районы
Советының
21.04.20021 ел, № 8-59
карарына кушымта

Нигезләмә
«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып баруның эчтәлеген һәм тәртибен билгели.

1.2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең реестрлары (алга таба – Реестр) «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында (алга таба – җирле үзидарә органнары) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси эшләреннән мәгълүматлар нигезендә формалаша.

1.3. Реестрлар «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре Реестрын (алга таба – Җыелма Реестр) төзи, ул җирле үзидарә органнары киселешендә муниципаль хезмәткәрләр турында белешмәләрнең җыелма исемлегеннән гыйбарәт.

1.4. Реестрга һәм Җыелма реестрга кертелгән белешмәләр федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләргә, ә башка очракларда конфиденциаль характердагы белешмәләргә керә һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә саклanырга тиеш.

1.5. Реестрлар һәм Җыелма Реестр «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» (алга таба – Мәгълүмат системасы) Татарстан Республикасы дәүләт Мәгълүмат Системасында, аларда булган мәгълүматны рөхсәтсез керү, юк итү, модификацияләү, блоклау, күчерү, бирү, тарату, шулай ук башка законсыз гамәлләрдән саклауны тәэмин итү белән алып барыла.

## II. Реестрларны һәм Җыелма реестрны алып бару

2.1. Реестрны алып бару мәгълүмат системасында кадрлар эше (алга таба – кадрлар хезмәте) алып бару өчен җаваплы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы хезмәткәре яисә бүлекчәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.2. Җыелма реестрны формалаштыру һәм алып бару Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар секторы тарафыннан Мәгълүмат системасында кадрлар хезмәтләре тарафыннан бирелгән Реестрлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.3. Реестрның һәм Җыелма Реестрның формасы дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты тарафыннан расланган формага туры килә һәм Мәгълүмат системасында урнаштырыла.

2.4. Реестр һәм Җыелма Реестр үз эченә түбәндәгеләрне ала:

муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары;

муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт башкаручы җирле үзидарә органының исеме;

әлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәсенең исеме;

Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте вазыйфаларының расланган Реестры нигезендә муниципаль хезмәткәр биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы исеме;

- муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттәге кадрлар резервына кертү (кадрлар резервына кертү датасы, вазыйфаның атамасы, кадрлар резервына кертү нигезе, кадрлар резервыннан төшереп калдыру нигезе).

2.5. Муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматларына түбәндәгеләр керә:

муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме(булганда);

туган көне;

һөнәри белеме турында мәгълүмат (белем бирү оешмасының исеме, диплом номеры һәм датасы, белгечлек һәм квалификация);

хәрби хезмәт үтү турында;

яңадан һөнәри әзерлек узу турында (белем бирү оешмасы исеме, уку тәмамлану датасы, программаның исеме, йомгаклау документының төре һәм номеры);

квалификация күтәрү турында (белем бирү оешмасының исеме, уку тәмамлану датасы, программаның исеме, йомгаклау документының төре һәм номеры);

гыйльми дәрәҗә турында (гыйльми дәрәҗә исеме, бирү датасы);

гыйльми исем турында (гыйльми исемнең атамасы, бирү датасы);

елларда, айларда, көннәрдә исәпләнгән гомуми хезмәт стажы турында;

елларда, айларда, көннәрдә исәпләнгән муниципаль хезмәт стажы турында;

аттестация узу турында (аттестация үткәрү датасы, аттестация комиссиясе карары);

класс чины турында (класс чины, аны бирү турында актның датасы һәм номеры);

дәүләт бүләкләре һәм башка бүләкләр турында (бүләк төре, бүләкләү датасы);

муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс узу турында (әгәр граждан үз вазыйфасына конкурс нәтиҗәләре буенча билгеләнгән булса);

хезмәт контракты турында (хезмәт контрактын төзү төре, датасы, аның гамәлдә булу вакыты, аңа үзгәрешләр кертү датасы).

Муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси мәгълүматларының әлеге исемлеге тулы исемлек булып тора һәм Реестрга һәм Җыелма реестрга карата гына билгеләнә.

2.6. Муниципаль хезмәткә керүче граждан турындагы мәгълүмат системасына белешмәләр эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле акты нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәннән соң ике эш көне эчендә Реестрга кертелә.

2.7. Муниципаль хезмәткәр шул ук җирле үзидарә органында муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына билгеләгәндә, аның муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнүе турындагы мәгълүматлар эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле акты нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәннән соң ике эш көне эчендә Реестрга кертелә.

2.8. Муниципаль хезмәткәр турында белешмәләрне Реестрдан һәм Җыелма реестрдан төшереп калдыруга нигез булып, аны эштән азат итү, муниципаль вазифага яки муниципаль хезмәт вазыйфасы булмаган вазыйфага билгеләнү, үлем (һәлак булу), шулай ук затны законлы көченә кергән суд карары нигезендә хәбәрсез югалган яисә вафат булган дип тану тора.

Муниципаль хезмәткәр турында белешмәләрне Реестрдан төшереп калдыру өчен шулай ук аның башка җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнүе дә нигез булып тора.

Күрсәтелгән нигезләр буенча муниципаль хезмәткәр турында белешмәләр эштән азат ителгән, бүтән җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгән , муниципаль вазыйфа яисә муниципаль хезмәт вазыйфасы булмаган вазыйфага билгеләнгән, үлем (вафат булу) көненнән соң килүче көнне, яисә тиешле суд карары законлы көченә кергән көндә Реестрдан алына.

2.9. Реестрдагы тиешле үзгәрешләр турында белешмәләр Мәгълүмат системасына кертелә.

2.10. Реестрларны һәм Җыелма реестрны алып бару белән бәйле бәхәсләр закон нигезендә хезмәт бәхәсләре буенча комиссияләр һәм суд тарафыннан карала.

## III. Татарстан Республикасы «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең реестрларын алып баруны тикшереп тору

3.1. Реестрларны алып баруны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органы җитәкчесе контрольдә тота. Җыелма реестрны алып баруны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе контрольдә тота. Контроль шәхси эшләрнең һәм аларның торышын тикшерү, муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси мәгълүматларын үз эченә алган мәгълүматларны Реестрдагы мәгълүматлар белән чагыштыру формасында башкарыла.

Мәгълүматларны чагыштыру факты тиешле актта чагылыш таба.

3.2. Реестрларны һәм Җыелма реестрны формалаштыру һәм алып бару бурычы йөкләнгән кадр хезмәтләре мәгълүматларның дөреслеге, мәгълүматларны үз вакытында кертү, конфиденциаль характердагы белешмәләрне һәм дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне тарату өчен закон нигезендә җаваплы.

## IV. Реестрларны саклау

4.1. Реестрлар һәм Җыелма реестрлар, аларга карата үзгәрешләр, аларда булган мәгълүматка рөхсәтсез керү, юк итү, модификацияләү, блоклау, күчермәләү, бирү, тарату, шулай ук башка законсыз гамәлләрдән саклауны тәэмин итеп, Мәгълүмат системасында саклана.